МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 1509/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«14» 10 2025

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 21.05.2025 ел, №641/о боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31, 32, 33 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023, 2024 һәм 2025 елларда җирдән файдалануның һәм төзелешнең генераль планнарына һәм кагыйдәләренә иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар уздырмыйча гына үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында» 2023 елның 28 гыйнварындагы 63 номерлы карары, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү хакында» 2025 елның 25 сентябрендәге 1405/о номерлы боерыгы, Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе утырышының 2025 елның 11 сентябрендәге 50

номерлы беркетмәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 21.05.2025 ел, №641/о боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәреш кертеп, 19 статьяның 8 пунктында китерелгән таблицага түбәндәге юлдан соң

«

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3.6.2. | Мәдәният һәм ял парклары | б-мәгән | б-мәгән | б-мәгән | б-мәгән |

»

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

«

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3.8.1. | Дәүләт идарәсе | б-мәгән | б-мәгән | б-мәгән | б-мәгән |

»

2. Территорияләрне үстерү департаменты Аломерацияләрне үстерү идарәсенең Казан агломерациясен үстерү бүлегенә (Р.А. Мәмәтовага) тәэмин итәргә:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрүне;

әлеге боерыкны үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

әлеге боерыкны «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыруны;

әлеге боерыкны ул басылып чыккан көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча Территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыруны.

3. Юридик бүлеккә (Р.И. Кузьминга) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А. Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары | Отдел контроля исполнения документов | В.Н.Кудряшев